ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 155-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин һәм К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 155-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 546-VII ДС

155-1

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
Л.А. Якунин,
К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 73 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары һәм Хезмәт Даны орденының өч дәрәҗәсе белән бүләкләнгән гражданнар;»;

2) 5 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Транспорт салымы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актлары аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Шулай итеп, Федераль законда транспорт салымын түләүдән азат итү рәвешендә федераль салым ташламасы түбәндәгеләр өчен билгеләнгән:

– махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары – 2022 елның салым чорыннан;

– Советлар Союзы Геройлары һәм Россия Федерациясе Геройлары, шулай ук Дан орденының өч дәрәҗәсе белән бүләкләнгән затлар – 2026 елның салым чорыннан.

Шулай ук күрсәтелгән салым ташламасы салым түләүченең сайлавы буенча бер транспорт чарасына карата салым ташламалары куллану өчен нигезләрнең санына карамастан бирелә дип каралган.

Югарыда билгеләнгән гражданнар өчен транспорт салымы буенча ташлама бирү федераль закон нормалары белән җайга салынганга күрә, региональ законнарда да шундый ук җайга салуны саклап калу артык булып тора.

Шуңа бәйле рәвештә әлеге закон проекты белән «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү каралган, ул үзгәрешләр кабатлана торган нормаларны, ә атап әйткәндә, ташламага хокукы Россия Федерациясе Салым кодексы белән гарантияләнгән гражданнар категорияләрен искә алуны төшереп калдыру максатыннан кертелә.

Моннан тыш, закон проектында Социалистик Хезмәт Геройлары белән берлектә шулай ук Россия Федерациясе Хезмәт Геройларын салым түләүдән азат итү тәкъдим ителә. Әлеге бүләкләрнең икесе дә дәүләт һәм халык алдындагы аерым хезмәт казанышлары өчен дәүләт бүләкләре булып тора.

**«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Транспорт салымы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.

Россия Федерациясе Хезмәт Геройларына транспорт салымы буенча ташлама бирү аркасында керми калган керемнәр 92,6 мең сум күләмендә бәяләнә.